РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422057, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19а
тел. (84362)2-23-23

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422057, Татарстан Республикасы,
Саба районы, Тимершык авылы,
Пионер урамы, 19а
тел. (84362)2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
03.04.2026

КАРАР
№11

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 12.11.2025 №10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Төзелеш Министрлыгының «Дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының типовой индикаторларын раслау турында» 2025 елның 20 маендагы 301/пр номерлы боерыгы, РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 сентябрендәге 1670 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2025 елның 12 ноябрендәге 1783 номерлы карары нигезендә, Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 12.11.2025 №10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.9 һәм 1.10 пунктлар өстәргә:

«1.9. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда Контроль органы, шулай ук контроль чаралар уздыруга җәлеп ителә торган белгечләр, экспертлар тарафыннан рәсмиләштерелә торган документлар электрон документ рәвешендә төзелә һәм көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана.

1.10. Профилактик визит үткәрү турында, кисәтү игълан итү турында, контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль чараны үткәрү турында карарлар, контроль чараның, профилактик чараның актлары (шул исәптән уздыру мөмкинлеге булмау турындагы актлар), ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләр контроль чараларның бердәм реестрына

алар турында белешмәләр (күзәтчелек) чаралары һәм аларга имза салу кертү юлы белән рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән карарларны, актларны һәм күрсәтмәләрне рәсмиләштерү өчен документны аерым төзү таләп ителми.»;

1.2. 2.4. нче пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә өстәргә:

«Контроль объекты контроль төрләренең бердәм реестрына белешмәләр кертелгәннән соң хәвеф-хәтәр категорияләренең берсенә кертелгән дип санала.»;

1.3. 3.3.3. пунктта «кисәтүгә карата» сүзләреннән соң «, шул исәптән бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша» сүзләрен өстәргә;

1.4. 3.4.2. пунктының 1) пунктчасында «видео-конференц-элемтә,» сүзеннән соң «Инспектор» мобиль кушымтадан файдалану» сүзләрен өстәргә,»;

1.5. 4.5.5. нче пунктка түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

«Документлар буенча тикшерелгәндә документлар контрольдә тотылучы затлар тарафыннан бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан яисә «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып тапшырылырга мөмкин;

1.6. 4.9.2 пунктының икенче абзацын «карау гамәлгә ашырылырга мөмкин» сүзләреннән соң «, шул исәптән пилотсыз аппаратлар (системалар) кулланып» сүзләрен өстәргә;

1.7. 4.2.5 пунктының икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә өстәргә: «Шул ук вакытта 248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракларда прокуратура органнары белән килештерү таләп ителми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Тимершык авыл
җирлеге Башлыгы — А.Х. Хаҗиев